| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 14 апрель № 228

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына теркәлгән Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына беркетелә торган җирле бюджетлар керемнәре чыганаклары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 март, 143 нче; 2013 ел, 24 май, 348 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 51 нче; 2014 ел, 11 август, 583 нче; 2015 ел, 18 май, 353 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 645 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 780 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) теркәлгән Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына беркетелә торган җирле бюджетлар керемнәре чыганаклары исемлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 10 нчы пункт өстәргә:

«10. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына беркетелә торган керемнәр чыганаклары:

1) шәһәр округлары бюджетларына исәпләнә торган акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм китергән зыянны каплау өчен бүтән суммалардан башка кертемнәр;

2) муниципаль районнар бюджетларына исәпләнә торган акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм китергән зыянны каплау өчен бүтән суммалардан башка кертемнәр.».

2. Бу карар 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\228.doc